| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

# Об отмене карантина, установленного на территориях некоторых населенных пунктов Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных

В связи с истечением двух месяцев со дня последнего случая заболевания животных бешенством и выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Отменить карантин, установленный в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных на территориях следующих населенных пунктов Республики Татарстан:

село Арбор Балтасинского района;

село Новая Мурзиха Елабужского района.

2. Признать утратившими силу:

Указ Президента Республики Татарстан от 5 августа 2017 года № УП-663 «Об установлении карантина на территории села Новая Мурзиха Елабужского района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных»;

Указ Президента Республики Татарстан от 9 сентября 2017 года № УП-805 «Об установлении карантина на территории села Арбор Балтасинского района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** — **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
13 ноября 2017 года
№ УП-1002

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:
Балтач районының Арбор авылы;
Алабуга районының Яңа Мурзиха авылы.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:
Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Алабуга районының Яңа Мурзиха авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2017 елның 5 августындагы ПУ-663 номерлы Указы;
Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Балтач районының Арбор авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2017 елның 9 сентябрендәге ПУ-805 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 13 ноябрь
№ ПУ-1002